**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 июль № 541

г. Казань

«Е.Н.Батенчук исемендәге Чаллы икътисад-төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен һәм «Чаллы төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләрне һәм урта звено белгечләрен әзерләү сыйфатын күтәрү, кадрларны әзерләү күләмнәрен арттыру һәм хезмәт ресурсларыннан нәтиҗәлерәк файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Е.Н.Батенчук исемендәге Чаллы икътисад-төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – Е.Н.Батенчук исемендәге Чаллы икътисад-төзелеш көллияте) һәм «Чаллы төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – Чаллы төзелеш көллияте) бер-берсенә кушу юлы белән, эшчәнлекләренең төп максатларын саклап һәм алар нигезендә «Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте) төзеп, үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте Чаллы төзелеш көллиятенең һәм Е.Н.Батенчук исемендәге Чаллы икътисад-төзелеш көллиятенең хокуклы дәвамчысы булып тора;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, гамәлгә куючының

дәүләт йөкләмәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән ел саен раслана торган урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнардан һәм һөнәри белем бирү оешмалары мөлкәтен карап тоту нормативларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллиятен гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле, законнар белән күздә тотылган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон һәм «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәп, Чаллы төзелеш көллиятендә һәм Е.Н.Батенчук исемендәге Чаллы икътисад-төзелеш көллиятендә укучыларны ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, укыту шартларын һәм программаларын саклап, Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллиятенә күчерүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

ике ай эчендә Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте уставын эшләргә һәм расларга;

30 көн эчендә Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) дәүләт йөкләмәсен эшләргә.

4. Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте уставы дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

30 көн эчендә элек оператив идарә хокукында Чаллы төзелеш көллиятенә һәм Е.Н.Батенчук исемендәге Чаллы икътисад-төзелеш көллиятенә беркетелгән, эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә хокукында Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллиятенә беркетергә;

60 көн эчендә Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллиятенә беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Е.Н.Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллияте уставын раслаганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына аны әлеге карарның 1 нче пунктына

туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\541.doc